**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ГЛАВА**
**СТАРОУТЯМЫШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Мусы Джалиля, д.52, с.Старый Утямыш,
Черемшанский район,423105

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

Муса Җәлил урамы, 52 йорт, Иске Үтәмеш авылы,
Чирмешән районы, 423105

тел./факс (84396) 2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

**№ 1** **2018елның 24апреленнән**

**«Чегодай нефть ятмасының территориясен төзекләндерү» объекты (2 нче чират)» һәм территорияләрне планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

**КАРАР**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә, Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 26 мартындагы 148 номерлы карары нигезендә **Карар бирәм:**

1. 2018 елның 10 маенда «Чегодай нефть ятмаларын төзекләндерү» (2 чират) мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны билгеләргә

2. Ачык тыңлауларны күрсәтелгән көнне 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр үткәрелүен билгеләргә. Ачык тыңлаулар үткәрү урыны 423105, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан Иске Үтәмеш авыл җирлеге башлыгы кабинеты.

3. Проектны исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Мингулов Р. С. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге башлыгы;

Вафина З.Т. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – эшче төркем секретаре.

4. Билгеләргә:

а) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясында һәм Иске Үтәмеш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләр әлеге карар белән билгеләнгән ачык тыңлауларда катнашу юлы белән проект буенча фикер алышуда катнашалар

б) Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең халык алдында чыгарылган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәрен кабул итү, карау һәм исәпкә алу алып барыла;

в) Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең («халык алдында тыңлауларга» дигән тамга белән) 2018 елның 4 маена кадәр эш көннәрендә 10.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423105, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52.

Тәкъдимнәр шулай ук Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан почта аша күрсәтелгән адрес буенча җибәрелә ала.

г) Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең халык алдында тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча язмача тәкъдимнәрен алдан караганда, ачык тыңлаулар барышында карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләр арасыннан төшереп калдырыла:

- аноним тәкъдимнәр;
- әлеге карар нигезендә гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләгә кагылмаган тәкъдимнәр;
- 2018 елның 10 маенда 14.00 сәгатьтән соң килгән тәкъдимнәр.

5. Иске Үтәмеш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең халык алдында тыңлауларда катнашырга теләк белдерүләре (кызыксынган затның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, туган көнен, яшәү урынын, төрен, сериясен һәм шәхесен таныклаучы документның номерын күрсәтеп), кызыксынган затның шәхесен таныклаучы документның кем һәм кайчан бирелүе турында белешмәләр 2018 елның 10 маена кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423105, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

7. Әлеге карарны норматив-хокукый актларны халыкка җиткерү өчен мәгълүмат стендында һәм Иске Үтәмеш авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://cheremsan ktatarstan. ru

Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы башлыгы Мингулов Р. С.